КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 31 октябрь г.Казань № 951

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче;

2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче; 2013 ел, 11 май, 313 нче; 2013 ел, 29 июнь, 455 нче; 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче; 2014 ел, 28 май, 362 нче; 2014 ел, 25 август, 613 нче; 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче; 2015 ел, 4 август, 565 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1025 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 611 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 983 нче; 2017 ел, 18 май, 292 нче; 2017 ел, 27 сентябрь, 731 нче; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2017 ел, 31 октябрь, 827 нче; 2017 ел, 11 ноябрь, 885 нче; 2018 ел, 22 гыйнвар, 27 нче; 2018 ел, 26 апрель, 293 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 953 нче; 2018 ел, 27 декабрь, 1247 нче; 2019 ел, 13 июль, 578 нче; 2019 ел, 28 август, 730 нчы; 2019 ел, 18 октябрь, 938 нче; 2019 ел, 29 октябрь, 967 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1176 нчы; 2020 ел, 28 май, 433 нче; 2020 ел, 29 июнь, 539 нчы; 2020 ел, 8 июль, 568 нче; 2021 ел, 4 февраль, 54 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 16 август, 737 нче; 2021 ел, 23 сентябрь, 903 нче; 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы; 2022 ел, 30 май, 499 нчы; 2022 ел, 20 июнь, 587 нче; 2022 ел, 15 июль, 683 нче; 2022 ел, 12 август, 797 нче; 2022 ел, 14 сентябрь, 1002 нче; 2022 ел, 20 сентябрь, 1018 нче; 2022 ел, 11 октябрь, 1093 нче; 2022 ел, 8 ноябрь, 1184 нче; 2022 ел, 21 ноябрь, 1249 нчы; 2023 ел, 21 февраль, 171 нче; 2023 ел, 10 август, 968 нче; 2023 ел, 25 сентябрь, 1183 нче; 2023 ел, 1 ноябрь, 1390 нчы; 2023 ел, 18 ноябрь, 1487 нче; 2023 ел, 27 декабрь, 1696 нчы; 2024 ел, 10 апрель, 247 нче; 2024 ел, 11 июнь, 419 нчы; 2024 ел, 17 июнь, 431 нче; 2024 ел, 15 август, 659 нчы; 2024 ел, 4 сентябрь, 730 нчы; 2024 ел, 25 октябрь, 920 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика башкарма хакимият органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7.4 пунктның дүртенче абзацында «6 нчы кушымтасында» сүзләрен «2 нче, 6 нчы кушымталарында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге Нигезләмәнең 11 нче кушымтасындагы 69 нчы юлын төшереп калдырырга.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Республика башкарма хакимият органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 31 октябрь, 951 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләрнең тәкъдим ителә торган күләмнәре

| Түләү коды | Компенсация характерындагы түләүләр билгеләү өчен нигез | Компенсация характерындагы түләүләр билгеләнә торган вазыйфалар | | Компенсация характерындагы түләүләр хокукына ия бүлек (кабинет) коды* | Өстәмә түләү күләме | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | һөнәри квалификация төркеменең исеме | вазыйфа исеме | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 69 | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» | Табиблар һәм провизорлар | медицина диагностика тикшеренүләрен дистанцион укуны турыдан- | - | 190 | процент |
| | | Учреждениеләрнең югары | | | 190 | процент |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | дәүләт автоном учреждениесендә эшләү | медицина һәм фармацевтика белемле структур бүлекчәләр җитәкчеләре (табиб-белгеч, провизор) | туры гамәлгә ашыручы персонал | | | |
| 101 | Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелгән медицина ярдәме төрләре буенча медицина хезмәтләре күрсәтү буенча амбулатория-поликлиника оешмаларында (структур бүлекчәләрдә) эшләү | Табиблар һәм провизорлар | участок табиб-терапевтлары;<br>участок табиб-педиатрлары;<br>гомуми практика табиблары (гаилә табиблары) (дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән табиб-белгечләрдән башка) | 62, 76, 116, 134 | 15 000 | сум |
| | | Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | участок шәфкать туташы (участок медицина браты) | | 6 750 | сум |
| | | | гомуми практика табибының (гаилә табибының) шәфкать туташы (гомуми практика табибының (гаилә табибының) медицина браты) | | 6 750 | сум |
| 102 | Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелгән | Урта медицина һәм фарма- | медицина шәфкать туташы (медицина браты), патронаж медицина | 119 | 2 500 | сум |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | медицина ярдәме төрләре буенча медицина хезмәтләре күрсәтү буенча фельдшер-акушерлык пунктларында эшләү | цевтика персоналы | шәфкать туташы (патронаж медицина браты) | | | |
| | | | фельдшер, акушер (акушерка) | | 3 500 | сум |
| | | | фельдшер-акушерлык пункты мөдире – фельдшер (акушер (акушерка)), шәфкать туташы (медицина браты) | | 3 500 | сум |
| 103 | Ашыгыч медицина ярдәме станцияләрендә (бүлекләрендә) эшләү | Учреждениеләрнең югары медицина һәм фармацевтика белемле структур бүлекчәләр җитәкчеләре (табиб-белгеч, провизор) | структур бүлекчә (бүлек, бүлекчә, лаборатория, кабинет, отряд һ.б.) мөдире (стационарларның хирургия профиле бүлекләре мөдирләреннән башка) | 117 | 9 000 | сум |
| | | Табиблар һәм провизорлар | ашыгыч медицина ярдәме станцияләренең (бүлекләренең) табиб-белгечләре | | 9 000 | сум |
| | | | табиб – анестезиолог-реаниматолог, өлкән табиб | | 9 000 | сум |
| | | Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | шәфкать туташы (медицина браты), чакыруларны кабул итү һәм аларны күчмә брига- | | 5 400 | сум |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | даларга тапшыру буенча шәфкать туташы (чакыруларны кабул итү һәм аларны күчмә бригадаларга тапшыру буенча медицина браты), шәфкать туташы – анестезист (медицина браты – анестезист), өлкән медицина шәфкать туташы (өлкән медицина браты) | | | |
| | | | фельдшер, акушер (акушерка), өлкән акушер (өлкән акушерка), өлкән фельдшер, чакыруларны кабул итү һәм күчмә бригадаларга тапшыру буенча фельдшер | | 6 300 | сум |
| 104 | Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелгән медицина ярдәме төрләре буенча беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче оешмаларда эшләү (поликлиникалар, көндезге стационарлар, алар | Учреждениеләрнең югары медицина һәм фармацевтика белемле структур бүлекчәләр җитәкчеләре (табиб-белгеч, провизор) | табиб-белгечләрнең функциональ вазыйфаларын үтәү шарты белән структур бүлекчәләр (бүлек, бүлекчә, лаборатория, кабинет, отряд һ.б.) мөдирләре (стационарның хирургия профиле бүлекләре мөдирләреннән башка) | 5, 6, 7, 8, 9, 10, 11, 14, 17, 20, 21, 24, 30, 32, 33, 35, 36, 40, 50, 55, 59, 60, 62, 68, 69, 70, 71, 73, 76, 78, 79, 85, 86, 87, 88, 92, 93, 97, 99, 101, 102, 103, 104, 105, 106, 107, | 6 570 | сум |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | янындагы өйләрдә стационарлар)** | Табиблар һәм провизорлар | табиб-белгечләр (участок табиб-терапевтлары, участок табиб-педиатрлары, гомуми практика табиблары (гаилә табиблары), табиб-фтизиатрлар, табиб-психиатрлар, табиблар – психиатр-наркологлар, табиблар – суд-медицина экспертларыннан башка) | 108, 109, 111, 112, 113, 116, 120, 124, 125, 126, 127, 128, 129, 130, 131, 133, 136, 139, 144, 146, 147, 148, 149, 157 | 6 570 | сум |
| | | Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | урта медицина персоналы (участок табиб-терапевтларының участок шәфкать туташлары (участок медицина братлары), участок табиб-педиатрларының участок шәфкать туташлары (участок медицина братлары), гомуми практика табибларының (гаилә табибларының) шәфкать туташлары (гомуми практика табибларының медицина братлары (гаилә табиблары)), табиб-фтизиатрларның | | 2 160 | сум |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәфкать туташлары (медицина братлары), табиб-психиатрларның шәфкать туташлары (медицина братлары), табибларның – психиатр-наркологларның шәфкать туташлары (медицина братлары), фельдшер-акушерлык пунктларының урта медицина персоналыннан башка) | | | |
| 105 | Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелгән медицина ярдәме төрләре буенча медицина хезмәтләре күрсәтү буенча стационар оешмаларда (структур бүлекчәләрдә, көндезге стационарларны да кертеп) эшләү*** | Учреждениеләрнең югары медицина һәм фармацевтика белемле структур бүлекчәләр җитәкчеләре (табиб-белгеч, провизор) | структур бүлекчәләр мөдирләре (табиб-белгечләрнең функциональ бурычларын үтәү шарты белән) | 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12, 13, 14, 15, 16, 17, 18, 19, 21, 22, 24, 25, 26, 27, 28, 29, 30, 31, 32, 33, 34, 36, 37, 38, 39, 40, 41, 42, 43, 44, 45, 46, 47, 48, 50, 52, 53, 54, 55, 56, 57, 59, 60, 61, 62, 63, 64, 65, 67, 69, 70, 71, 73, 76, 77, 78, 79, 85, 87, 88, 89, 90, 91, 92, 93, 94, 97, 101, 102, 103, | 1 800 | сум |
| | | Табиблар һәм провизорлар | табиб-белгечләр | | 1 800 | сум |
| | | Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | урта медицина персоналы | | 900 | сум |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 104, 105, 106, 107, 108, 109, 111, 112, 113, 114, 115, 117, 124, 125, 126, 127, 128, 129, 137, 138, 139, 142, 144, 147, 149, 150, 151, 152, 153, 155, 156 | | |
| 106 | Анестезиология-реанимация бүлекләрендә һәм реанимация һәм интенсив терапия палаталарында эшләү | Учреждениеләрнең югары медицина һәм фармацевтика белемле структур бүлекчәләр җитәкчеләре (табиб-белгеч, провизор) | структур бүлекчәләр мөдирләре | 39, 41, 42 | 3 000 | сум |
| | | Табиблар һәм провизорлар | табиб-белгечләр | | 3 000 | сум |
| | | Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | урта медицина персоналы | | 2 000 | сум |
| 108 | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау | Учреждениеләрнең югары | структур бүлекчәләр мөдирләре | - | 10 000 | сум |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләү**** | медицина һәм фармацевтика белемле структур бүлекчәләр җитәкчеләре (табиб-белгеч, провизор) | | | | |
| | | Табиблар һәм провизорлар | табиб-белгечләр | | 10 000 | сум |

---

*Республика башкарма хакимият органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә 4 нче кушымта нигезендә.

**Тәүлек буе медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары структурасында беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче бүлекчәләр (тәүлек буе эшли торган стационарлардагы көндезге стационарлардан тыш ) булганда, әлеге бүлекчәләр хезмәткәрләренә өстәмә акча түләү әлеге кушымта буенча 104 нче код нигезендә башкарыла. Медицина оешмаларының тәүлек буе һәм беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче диагностика һәм параклиника бүлекләре хезмәткәрләренә өстәмәләр әлеге кушымта буенча 104 нче код нигезендә билгеләнә.

***Медицина оешмаларының бары тәүлек буе ярдәм күрсәтүче диагностика һәм параклиника бүлекләре хезмәткәрләренә өстәмәләр әлеге кушымта буенча 105 нче код нигезендә билгеләнә.

**** «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном учреждениесенең әлеге нигезләмәдә вазыйфалар исемлеге бирелгән хезмәткәрләренә акчалата түләүләр биләгән вазыйфа буенча эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә, әмма иң күбе бер ставка күләмендә гамәлгә ашырыла. Әгәр хезмәткәр тулы ай эшләмәгән (ялда, укуда, вакытлыча хезмәткә яраксызлык чорында һ.б. булган) очракта, акчалата түләү фактта эшләнгән вакыт өчен башкарыла.

---